КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 24 декабрь г.Казань № 1187

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламентын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Аппараты турында нигезләмәне раслау хакында» 2005 ел, 5 декабрь, 563 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламентын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Аппараты турында нигезләмәне раслау хакында» 2005 ел, 5 декабрь, 563 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 23 март, 157 нче; 2009 ел, 24 декабрь, 883 нче; 2010 ел, 14 июль, 563 нче; 2011 ел, 28 апрель, 344 нче; 2012 ел, 29 май, 435 нче; 2013 ел, 8 апрель, 238 нче; 2013 ел, 20 июнь, 424 нче; 2013 ел, 19 июль, 507 нче; 2013 ел, 30 сентябрь, 701 нче; 2013 ел, 25 ноябрь, 928 нче; 2014 ел, 28 февраль, 130 нчы; 2014 ел, 31 июль, 559 нчы; 2015 ел, 23 июнь, 452 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламентын яңа редакциядә (кararга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Аппараты турында нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Республика башкарма хакимият органнарына 30 көн эчендә норматив хокукый актларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламентына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Аппараты турындагы нигезләмәгә туры китерү хакында тәкъдимнәр кертергә.

3. Бу карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе Ш.Х.Гафаровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин